Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегенең
Сиктерме-Хузангай авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

2019 елның 28 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 20 номерлы Әлки муниципаль районының «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, 2019 елның 28 ноябрендәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегенең Сиктерме-Хузангай авылында гражданнар җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге составына керүче Сиктерме-Хузангай авылындагы гражданнар җыенын узган, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, аларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар, көндезге формада укучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- төзелешкә, суэтем челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен һәм су белән тәэмин итү белән бәйле чыгымнарны башкаруга, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга, су башнялары территориясен коймаларга һәм буяуга һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләргә-90 сум;
- кирәкле материал (яктырткычлар) сатып алуга, урамнарны яктырту җайланмаларын урнаштыруга, яктырту җайланмасын урнаштыру буенча электр монтажы эшләренә һәм урамда яктыртуның кулланыла торган энергиясе өчен чыгымнарны түләүгә - 90 сум;
- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тотуга (грунт, ком, вак таш өю, торак пунктлар эчендәге юлларны һәм урамнарны чүп-чардан арындыруга, кышын урамнарны кардан чистартуга)-270 сум;
- гыйбадәт йортын төзекләндерү һәм төзү, зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту өчен -80 сум;

- чүплекләрне өемнәргә өюгә, чүп-чарны утильләштерүгә, контейнерлар сатып алу өчен чүп-чар җыю мәйданчыкларын төзекләндерүгә - 70сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, аларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар, көндезге формада укучы студентлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- төзелешкә, суэтем челтәрләрен реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен һәм су белән тәэмин итү белән бәйле чыгымнарны башкаруга, урамдагы су белән тәэмин итү системасын ремонтлауга, су башнялары территориясен коймаларга һәм буяуга һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләргә-90 сум;

- кирәкле материал (яктырткычлар) сатып алуга, урамнарны яктырту җайланмаларын урнаштыруга, яктырту җайланмасын урнаштыру буенча электр монтажы эшләренә һәм урамда яктыртуның кулланыла торган энергиясе өчен чыгымнарны түләүгә - 90 сум;

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тотуга (грунт, ком, вак таш өю, торак пунктлар эчендәге юлларны һәм урамнарны чүп-чардан арындыруга, кышын урамнарны кардан чистартуга)-270 сум;

-гыйбадәт йортын төзекләндерү һәм төзү, зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту өчен -80 сум;

- чүплекләрне өемнәргә өюгә, чүп-чарны утильләштерүгә, контейнерлар сатып алу өчен чүп-чар җыю мәйданчыкларын төзекләндерүгә - 70сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Карата авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Иске Карата авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Кузнецов